РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 17 декабре 81-2 номерлы

ТР Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге
Совет депутаты статусы турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» һәм 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федерал законнар нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында» 2017 елның 31 июлендәге 35-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 10 статьяда:

1 өлешнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«8) Үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә. Депутат, шул исәптән үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы Депутат, депутат сайланган көннән алып дүрт ай эчендә, үзенә вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру туктатылганнан соң, шулай ук хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр булган очракта, күрсәтелгән мәгълүматларны, ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра. Хисап чоры дәвамында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы Президентына) хәбәр итә.»;

1.2. 11 Статьяда:

түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«11 Статья. Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр.

1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән өчен, бу мәгълүматларны бозмаган очракта түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан даими нигездә азат итү, вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) вәкаләтләре вакыты туктатылганчы Советта вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.

2. Депутат статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.»;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru.) һәм “Интернет” телекоммуникацияләр челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru.) урнаштырыларга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы,
Буа муниципаль районы,
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы
Советы Рәисе И.И. Галиуллин